СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
«28 » октябрь 2022 ел

КАРАР
№59

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советы "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарына Кече Лызи авыл җирлегенең аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында»

«Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районынын Кече Лызи авыл советы түбәндәге карарны кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитетының Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җеназа эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтне оештыру өчен шартлар тудыру, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибен билгеләү, күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү өлешендә ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру өчен шартлар тудыру.

2. Татарстан Республикасы Балтач район Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты белән килешү төзергә;

- әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында, бюджет законнары нигезендә 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында проект эшләргә һәм тәкдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан

Республикасы Балтач муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында рәсми «Интернет» сайтында (baltasi.tatarstan.ru) «җирлек» бүлегендә һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Нече Лызи авыл Советы Рәисе,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Нече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов